# *“Челтер чишмә”бәйрәме*
# *(авыл һәм  чишмә тарихы белән танышу)*

Чишмә урамында яшәүче ак әби Рузалия апа чишмә һәм Шыңар авылының килеп чыгу тарихын сөйли. Әнә еракта Шыңар бабай үзенең ике малае белән килә, аларның кечесе Мишә елгасының аскы ягына, ә олы улы Мишәнең өске ягына урнаша, менә шуннан Кече Шыңар һәм Олы Шыңар авыллары барлыкка килә. Ә менә бу чишмә урынында элек зур күл булган икән.











